ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

28.09.2023 д. им. М. Вахитова № 4

**Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 21 октябрендә 09 сәгать 00 минутка Мулланур Вахитов исемендәге авыл, Үзәк урамы, 24 йорт адресы буенча авыл клубы бинасында Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авыл гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләнергә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авылы җирлеге Мулланур Вахитов исемендәге авыл территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга риза булырсызмы:

- су җыю скважинасын ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф. Р. Кәримов